СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2019 Әгерҗе шәһәре № 42-3

Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелгән Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе

В.В. МАКАРОВ

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының 13.12.2019 № 42-3
Карары белән

Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлек бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын Баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында»2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Әгерҗе муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турында карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Граждан хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылу өлешендә субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

хезмәткә түләү һәм хезмәт өчен түләү хисаплау;

командировка чыгымнары;

элемтә хезмәтләре;
транспорт хезмәтләре;
коммуналь хезмәтләр;
мөлкәтне файдалану буенча хезмәтләр;
мөлкәтне карап тоту буенча эшләр, хезмәтләр;
башка эшләр, хезмәтләр;
төп чаралар сатып алу;
матди запаслар сатып алу;
салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр;
башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – Казначылык) җирлек бюджетлары үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачык булган шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет Казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләрнең бюджетлары чыгымнары турындагы хисапны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләрнең Башкарма комитетына тапшыралар.

12. Башкарма комитетка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемена күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң, килүче елның 1 гыйнварына кулланылмаган субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты һәм финанс органы контрольдә тота.